ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

4 март, 2024 ел № 32/7

Экологик экспертиза узарга тиешле
билгеләнгән хуҗалык һәм башка
эшчәнлек турында иҗтимагый фикер алышуны
оештыру һәм үткәрү тәртибен раслау хакында

«Экологик экспертиза турында» 1995 елның 23 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү материалларына таләпләрне раслау хакында» 2020 елның 1 декабрендәге 999 номерлы Россия Федерациясе Табигый байлыклар һәм экология министрлыгы боерыгы, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Экологик экспертиза узарга тиешле билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында иҗтимагый фикер алышуны оештыру һәм үткәрү тәртибен кушымтага нигезләнеп расларга.

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
32/7 Карарына кушымта
4 март 2024 ел

## Экологик экспертиза узарга тиешле билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында иҗтимагый фикер алышуны оештыру һәм үткәрү

### 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге тәртип «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ Федераль закон, «Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү материалларына таләпләрне раслау хакында» 2020 елның 1 декабрендәге 999 номерлы Россия Федерациясе Табигый байлыклар һәм экология министрлыгы боерыгы (алга таба - таләпләр), шәһәр Уставы нигезендә эшләнгән һәм экологик экспертиза узарга тиешле билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында иҗтимагый фикер алышуны оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

2. Билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында иҗтимагый фикер алышу һәркемнең уңайлы әйләнә-тирә мохиткә конституцион хокукларын гамәлгә ашыру, аның торышы турында дөрес мәгълүмат алу, шулай ук гражданнарның законнар нигезендә уңайлы мохиткә хокукларына кагылышлы карар кабул итүдә катнашуын тәэмин итү максатыннан үткәрелә.

3. Иҗтимагый фикер алышу формасы Башкарма комитет тарафыннан заказчы (башкаручы) белән килешеп билгеләнә:

1) гади мәгълүмат бирү (иҗтимагый фикер алышу объектының урнашу урынын күрсәтеп һәм адреска (адресларга), шул исәптән электрон почтага, искәрмәләр, комментарийлар һәм тәкъдимнәр җыю турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү), дәүләт экология экспертизасының тискәре нәтиҗәсе нигезендә яңадан эшләнгән, яки таләпләрнең 6 пункты нигезендә проект документациясе экспертизасы һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре буенча яңадан эшләнгән Техник бирем проекты, экологик экспертиза объекты турында, әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны алдан бәяләү материалларын да кертеп, иҗтимагый фикер алышу үткәрелгән очракта, шулай ук әгәр күрсәтелгән объектлар әйләнә – тирә мохиткә тискәре йогынты ясаучы объектларга, I -III категорияле объектларга кертү критерийларына туры килмәсә, билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлеккә карата әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаучы объектларда әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүнең материаллары белән, шулай ук мондый эшчәнлек «Экологик экспертиза турында» 1995 елның 23 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы

Федераль законда (алга таба – 174-ФЗ номерлы Федераль закон) билгеләнгән тәртиптә дәүләт экология экспертизасы каралмаса;

2) сораштыру (иҗтимагый фикер алышу объекты белән танышу урынын күрсәтеп, җәмәгатьчелек фикерләрен, комментарийларын һәм тәкъдимнәрен сораштыру кәгазьләре һәм сораштыру беркетмәсе төзеп җыю тәртибендә җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү);

3) җәмәгать тыңлаулары (иҗтимагый фикер алышу объекты белән танышу урынын, җәмәгать тыңлауларының датасын, вакытын һәм аны үткәрү урынын күрсәтеп, халыкка хәбәр итү, теркәлү кәгазьләре һәм җәмәгать тыңлаулары беркетмәсе язылa);

4) иҗтимагый фикер алышуның башка формалары (конференция, түгәрәк өстәл, анкета, халык белән консультацияләр, шулай ук бу пунктта күрсәтелгән формаларны берләштерү) җәмәгатьчелеккә иҗтимагый фикер алышу объекты белән таныштыруны, фикер алышу, комментарийлар һәм тәкъдимнәр туплау өчен материалларның урнашкан урынын күрсәтеп мәгълүмат бирү .

## 2 бүлек. Иҗтимагый фикер алышу инициаторлары

4. Иҗтимагый фикер алышу инициаторы - дәүләт экологик экспертиза объекты проекты заказчысы.

Бу очракта, заказчы - планлаштырылган (билгеләнгән) хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында документлар әзерләү өчен җаваплы, шул исәптән 174-ФЗ номерлы Федераль законда күрсәтелгән очракларда, планлаштырылган (билгеләнгән) хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында документлар тапшыру өчен җаваплы юридик яки физик зат.

Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү буенча эшләрне заказчы, шулай ук заказчы тарафыннан планлаштырылган (билгеләнгән) хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча эшләрне башкару хокукы бирелгән физик яки юридик зат башкара ала.

5. Иҗтимагый дискуссия инициаторлары:

1) иҗтимагый фикер алышуларның оештыру-техник һәм мәгълүмати эшен тәэмин итәләр;

2) дәүләти экология экспертизасы объекты проектларын, шул исәптән әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү буенча материалларның беренчел вариантын, әлеге Тәртипнең 9 пунктында билгеләнгән мәгълүмат басылып чыкканнан соң 30 календарь көн эчендә, әмма җәмәгатьчелек фикер алышулары тәмамлануга ике атнадан да соңга калмыйча, таныштыру һәм искәрмәләр бирү өчен җәмәгатьчелеккә тәкъдим итүне тәэмин итәләр.

6. Иҗтимагый фикер алышу турында карар кабул итү өчен инициатор Башкарма комитетка әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауны бәяләүнең башлангыч материаллары турында (яки әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауны бәяләү объекты, шул исәптән әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауны бәяләү материаллары турында) фикер алышу турында белдерү кәгазе җибәрә. (алга таба - җәмәгать фикер алышу объекты дип атала), анда күрсәтелә:

1) әйләнә - тирә мохиткә йогынтыны бәяләү буенча эшләрнең заказчысы һәм башкаручысы (юридик затлар өчен атама; шәхси эшмәкәрләр өчен фамилиясе, исеме

һәм атасының исеме (булган очракта); төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН) яки шәхси эшмәкәрнең төп дәүләт теркәве номеры (ОГРНИП); юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен салым түләүченең индивидуаль номеры (ИНН) эшмәкәрләр өчен; юридик һәм (яки) фактик адрес - юридик затлар өчен; яшәү урыны адресы - шәхси эшмәкәрләр өчен; контакт мәгълүматлары (телефон, электрон почта адресы (булган очракта), факс (булган очракта);

2) иҗтимагый фикер алышу оештыру өчен җаваплы Башкарма комитетның исеме, юридик һәм (яки) факттагы адресы, контакт мәгълүматлары (телефон һәм электрон почта адресы (булган очракта), факсы (булган очракта);

3) планлаштырылган (билгеләнгән) хуҗалык һәм башка эшчәнлек исеме;

4) планлаштырылган (билгеләнгән) хуҗалык һәм башка эшчәнлек максаты;

5) планлаштырылган (билгеләнгән) хуҗалык һәм башка эшчәнлекне тормышка ашыруның башлангыч урыны;

6) әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауны бәяләүнең планлаштырылган вакыты;

7) иҗтимагый фикер алышу объектының урыны һәм вакыты;

8) иҗтимагый фикер алышу уздыруның фаразланган формасы һәм вакыты, шул исәптән искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү формасы (иҗтимагый фикер алышу җәмәгать тыңлаулары формасында үткәрелгән очракта җәмәгать тыңлаулары үткәреләсе дата, вакыт, урын күрсәтелә; иҗтимагый фикер алышу сораштыру юлы белән үткәрелгән очракта үткәрү вакыты, шулай ук сораштыру кәгазьләрен, анкеталарны (әгәр ул иҗтимагый фикер объекты урнаштырылган урыннан аерылып торса һәм иҗтимагый фикер алышулар сораштыру яки анкета формасында үткәрелсә) урнаштыру һәм җыю, шул исәптән электрон формада);

9) заказчы (башкаручы) һәм Башкарма комитеттан җаваплы затларның контакт мәгълүматлары (телефон һәм электрон почта адресы (булган очракта);

10) заказчы (башкаручы) теләге буенча башка мәгълмат.

## 3 бүлек. Иҗтимагый фикер алышу үткәрү турында карар

7. Иҗтимагый фикер алышу үткәрү турында карар Башкарма комитет тарафыннан кабул ителә

8. Башкарма комитетның иҗтимагый фикер алышу үткәрү турында карарында түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) иҗтимагый фикер алышу темасы;

2) иҗтимагый фикер алышу датасы, вакыты, урыны һәм формасы;

3) планлаштырылган эшчәнлекнең исеме, максаты һәм урыны;

4) инициаторның (заказчының яки аның вәкиленең) исеме һәм адресы;

5) иҗтимагый фикер алышу оештыру өчен җаваплы орган;

6) искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кабул итү тәртибе һәм вакыты;

7) билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек материаллары белән танышу, сораштыру кәгазьләрен, анкеталарны җыю (әгәр иҗтимагый фикер алышу сораштыру яки анкета формасында үткәрелсә), шул исәптән электрон рәвештә, вакыты һәм урыны.

9. Башкарма комитетның иҗтимагый фикер алышу үткәрү турындагы карары иҗтимагый фикер алышу турында белдерү кәгазе кергән көннән алып 14 көн эчендә

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

10. Иҗтимагый фикер алышу үткәрү вакыты – белдерү кәгазендә күрсәтелгән адрес буенча җәмәгатьчелекнең иҗтимагый фикер алышу объектына (иҗтимагый фикер алышу объектының урнашкан урынына) керүен тәэмин итү көненнән башлап:

1) техник бирем проекты (заказчы аның буенча иҗтимагый фикер алышу турында карар кабул иткән очракта) яки әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаучы объектларда планлаштырылган (билгеләнгән) хуҗалык һәм башка эшчәнлеккә карата әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүнең беренчел материаллары буенча, әгәр күрсәтелгән объектлар әйләнә – тирә мохиткә тискәре йогынты ясаучы объектларның I-III категорияле объектларга кертү критерийларына туры килмәсә,, шулай ук мондый эшчәнлеккә «Экологик экспертиза турында» 1995 елның 23 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт экология экспертизасы каралмаса – кимендә 10 календарь көн;

2) әйләнә - тирә мохиткә йогынтыны бәяләүнең беренчел материаллары (яки экологик экспертиза объекты, шул исәптән әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүнең беренче материаллары) буенча – кимендә 30 календарь көн (җәмәгать тыңлаулары уздырылган көннәрне исәпкә алмыйча).

11. Иҗтимагый фикер алышуны экологик экспертиза планлаштырылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында иҗтимагый фикер алышу үткәрү комиссиясе (алга таба - комиссия) оештыра һәм үткәрә.

Комиссия составы Башкарма комитет карары белән раслана.

12. Комиссия компетенцияләре:

1) иҗтимагый фикер алышуны әзерләү һәм үткәрүнең эш планын төзү;

2) иҗтимагый фикер алышу инициаторлары тәкъдим иткән материалларны анализлау;

3) иҗтимагый фикер алышуга чыгарыла торган конкрет сораулар исемлеген билгеләү;

4) эксперт буларак иҗтимагый фикер алышуда катнашырга чакырылучы вазыйфаи затлар, белгечләр, оешмалар һәм башка җәмәгатьчелек вәкилләре исемлеген билгеләү һәм аларга фикер алышуга чыгарыла торган мәсьәләләр буенча үз тәкъдимнәрен бирүне сорап рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү;

5) иҗтимагый фикер алышуны оештыру һәм үткәрү;

6) иҗтимагый фикер алышуда кергән тәкъдимнәрне карау һәм гомумиләштерү;

7) иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре буенча бәяләмә ясау;

8) иҗтимагый фикер алышу беркетмәсен әзерләү.

13. Комиссия иҗтимагый фикер алышу инициаторы тарафыннан иҗтимагый фикер алышу үткәрү турында белдерү кәгазе бирелгән көннән алып ундүрт көн эчендә тәкъдим ителгән документларны карый һәм иҗтимагый фикер алышу билгеләү турында Башкарма комитет карары проектын әзерли.

14. Иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан иҗтимагый фикер алышу тәмамланганнан соң 5 эш көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә беркетмә төзелә, ул Башкарма комитет һәм заказчы (башкаручы) вәкилләре тарафыннан имзалана.

15. Иҗтимагый фикер алышу беркетмәсе планлаштырылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча материалларның ахыргы вариантына кушымталарның берсе буларак теркәлә.

16. Комиссия рәисе тарафыннан иҗтимагый фикер алышу беркетмәсе расланганнан соң өч көн эчендә Башкарма комитет иҗтимагый фикер алышу беркетмәсен иҗтимагый фикер алышу үткәрү инициаторына җибәрә.

## 4 бүлек. Иҗтимагый фикер алышу объекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кабул итү

17. Иҗтимагый фикер алышуда каралырга тиешле иҗтимагый фикер алышу объекты һәм мәгълүмати материалларны урнаштыру чорында физик һәм юридик затлар, иҗтимагый оешмалар карала торган иҗтимагый фикер алышу объекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне иҗтимагый фикер алышуны билгеләү турындагы карарда күрсәтелгән электрон почта аша комиссиягә кертергә хокуклы.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертү иҗтимагый фикер алышуны билгеләү турында мәгълүматны бастырып чыгару көненнән башлана һәм иҗтимагый фикер алышуны уздыру срогы ахырына кадәр ике эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

18. Тәртипнең 17 пункты нигезендә кертелгән искәрмәләр һәм тәкъдимнәр иҗтимагый фикер алышу предметына туры килергә тиеш. Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр иҗтимагый фикер алышу предметына туры килмәсә, комиссия мондый тәкъдимне яисә искәрмәне иҗтимагый фикер алышу беркетмәсенә теркәми.

19. Иҗтимагый фикер алышуда катнашучының дөрес булмаган мәгълүмат бирүе ачыкланган очракта тәртипнең 17 пункты нигезендә кертелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр каралмый. Иҗтимагый фикер алышу срогы тәмамланганнан соң кергән искәрмәләр һәм (яисә) тәкъдимнәр, аноним искәрмәләр һәм (яисә) тәкъдимнәр, цензурасыз яисә мыскыллаулы искәрмәләр һәм (яисә) тәкъдимнәр каралмый һәм исәпкә алынмый.

20. Тәртипнең 17 пункты нигезендә кертелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр теркәлергә, тәртипнең 19 пунктында каралган очрактан тыш, комиссия тарафыннан, мәҗбүри каралырга тиеш.

21. Иҗтимагый фикер алышуда катнашучылар идентификация максатларында үзләре турында түбәндәге мәгълүматлар тапшыра (мондый мәгълүматларны раслый торган документларны теркәп):

1) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, яшәү (теркәлү) урынының адресы − физик затлар өчен;

2) исеме, төп дәүләт теркәве номеры, урнашу урыны һәм адресы - юридик затлар өчен.

22. Иҗтимагый фикер алышуда катнашучыларның персональ мәгълүматларын эшкәртү «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

23. Кертелгән тәкъдимнәр комиссия әгъзалары тарафыннан Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, башка муниципаль хокукый актларга туры килү предметына өйрәнелә.

## 5 бүлек. Иҗтимагый фикер алышуны җәмәгать тыңлаулары формасында Үткәрү

24. Җәмәгать тыңлаулары формасында үткәрелгән иҗтимагый фикер алышуда 18 яшькә җиткән физик затлар һәм юридик затлар, шулай ук әлеге тәртипнең 17 пункты нигезендә иҗтимагый фикер алышуда катнашучы буларак теркәлгән иҗтимагый берләшмәләр, шул исәптән:

1) инициатор, заказчы, инвестор, әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясый ала торган планлаштырылган эшчәнлекне нигезләү материаллары проект документациясен һәм дәүләт экологик экспертизасына кирәкле башка документацияне эшләүче;

2) дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары;

3) билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең экологик, социаль һәм икътисадый нәтиҗәләре белән кызыксынган җәмәгатьчелек: яшәү яки килү урыны буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге белән чиктәш территорияләрдә теркәлгән, иҗтимагый фикер алышу көнендә эшкә сәләтле булган Россия Федерациясе гражданнары.

25. Җәмәгать тыңлаулары башланганчы, җәмәгать тыңлауларында катнашучылар теркәлергә тиеш. Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларны теркәүне комиссия башкара. Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларны теркәү җәмәгать тыңлаулары башланганчы бер сәгать алдан башлана.

26. Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларны теркәү вакытында физик затлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлү белән шәхесне раслаучы документ күрсәтәләр. Юридик затлар вәкилләре теркәлү вакытында юридик затның дәүләт теркәве турында таныклык, вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документлар, шәхесләрен раслаучы документлар күрсәтәләр.

27. Теркәлмәгән затлар җәмәгать тыңлауларына кертелми.

28. Комиссия рәисе җәмәгать тыңлауларын ача, аның темасын, җәмәгать тыңлауларына чыгарыла торган мәсьәләләр исемлеген, чыгышлар тәртибе һәм эзлеклелеге буенча комиссия тәкъдимнәрен, җәмәгать тыңлаулары докладчысын игълан итә, җәмәгать тыңлаулары секретаре белән таныштыра.

29. Җәмәгать тыңлаулары секретаре җәмәгать тыңлаулары беркетмәсен алып бара. Җәмәгать тыңлаулары беркетмәсенә комиссия секретаре һәм рәисе имза куя.

30. Комиссия рәисе чыгыш ясау өчен төп докладчыга, чыгыш ясау хокукына ия булган җәмәгать тыңлауларында катнашучыларга һәм чакырылган затларга чират буенча сүз бирә.

31. Һәр чыгыштан соң җәмәгать тыңлауларында катнашучылар докладчыга сорау бирергә хокуклы.

32. Чыгыш ясарга теләүчеләр санына бәйле рәвештә, комиссия рәисе җәмәгать тыңлауларында катнашучы теләсә кайсы чыгыш ясаучының чыгыш ясау вакытын чикләргә хокуклы. Комиссия рәисе җәмәгать тыңлауларында тәнәфес игълан итәргә хокуклы.

33. Фикер алышуны оештыру өчен чыгышлардан соң комиссия рәисе фикер алышуның кайсы мәсьәләдә алып барылуын игълан итә һәм үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукына ия булган җәмәгать тыңлауларында

катнашучыларга сүз бирә. Чакырылган затлар комиссия рәисе рөхсәте белән генә чыгыш ясыйлар.

34. Чыгыш ясау хокукына ия булган җәмәгать тыңлауларында катнашучының чыгышы тәмамлангач яки чыгыш ясау өчен бирелгән вакыт тәмамлангач, комиссия рәисе җәмәгать тыңлауларында катнашучыларга чыгыш ясаучының позициясе һәм (яки) дәлилләре буенча төгәллек кертүче сораулар бирү һәм сорауларга җавап бирү өчен өстәмә вакыт бирә. Сорауларга җавап бирү вакыты җәмәгать тыңлауларында катнашучының төп чыгышы вакытыннан артмаска тиеш.

35. Сораулар язмача һәм телдән бирелергә мөмкин. Язмача бирелгән сораулар комиссия рәисенә тапшырыла һәм телдән бирелгән сорауларга җавап биргәннән соң укыла.

36. Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар комиссиягә тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен җәмәгать тыңлаулары беркетмәсенә кертү өчен тәкъдим итәргә хокуклы.

37. Чыгыш ясау хокукына ия булган җәмәгать тыңлауларында катнашучы тәкъдимнәрен кире алырга һәм (яки) башка җәмәгать тыңлауларында катнашучылар тәкъдим иткән тәкъдимнәргә кушылырга хокуклы. Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның каралган мәсьәлә буенча позицияләрен үзгәртү турындагы карарлары җәмәгать тыңлаулары беркетмәсендә чагыла.

38. Җәмәгать тыңлаулары мәсьәләсе буенча чыгышлар тәмамланганнан соң, җәмәгать тыңлауларын үткәрү комиссисе рәисе катнашучыларга фикер алышу нәтиҗәләре буенча аларның позициясенең үзгәрү ихтималлыгы турында сорау белән мөрәҗәгать итә.

39. Җәмәгать тыңлаулары темасы буенча фикер алышу тәмамлангач, комиссия рәисе секретарьга җәмәгать тыңлаулары темасы буенча барлык мәсьәләләр каралганнан соң йомгаклау документында калган тәкъдимнәрне төгәлләү өчен сүз бирә.

40. Кергән барлык искәрмәләр, тәкъдимнәр һәм комментарийлар әлеге Тәртипнең 17 пункты нигезендә теркәлә.

41. Теләге булган барлык катнашучылар фикер алышу проектының асылы буенча үз фикерләрен белдергәннән соң җәмәгать тыңлаулары тәмамланган дип санала.

42. Җәмәгать тыңлаулары формасында үткәрелгән иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре буенча әлеге тәртипнең 14 пункты нигезендә беркетмә төзелә.

43. Җәмәгать тыңлаулары формасында үткәрелгән иҗтимагый фикер алышу беркетмәсендә булырга тиеш:

1) иҗтимагый фикер алышу объекты;

2) җәмәгать тыңлауларының датасы, урыны һәм вакыты турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү ысулы;

3) җәмәгать тыңлаулары уздырыласы көнгә кадәр 20 календарь көн һәм җәмәгать тыңлаулары уздырылган көннән соң 10 календарь көн эчендә җәмәгать өчен фикер алышу объекты буенча материалларның урыны (шул исәптән заказчы карары буенча “Интернет” челтәрендә) һәм җәмәгатьчелек өчен ачык булу вакыты;

4) җәмәгать тыңлауларын үткәрү көне, вакыты һәм урыны;

5) җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның гомуми саны;

6) җәмәгатьчелек һәм заказчы (башкаручы) арасында фикер каршылыклары предметы (булган очракта);

7) җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны аныклаучы башка мәгълүмат.

## 6 бүлек.Гади мәгълүмат бирү формасында иҗтимагый фикер алышу үткәрү

44. Гади мәгълүмат бирү формасында иҗтимагый фикер алышу җәмәгатьчелеккә иҗтимагый фикер алышу объектының урнашу урыны, искәрмәләр, комментарийлар һәм тәкъдимнәр җыю өчен адрес (адреслар), шул исәптән электрон почтаны күрсәтеп, мәгълүмат бирү юлы белән үткәрелә.

45. Гади мәгълүмат бирү формасында иҗтимагый фикер алышуда әлеге тәртипнең 24 пунктында күрсәтелгән затлар катнаша ала.

46. Гади мәгълүмат бирү формасында иҗтимагый фикер алышуда катнашучы физик затлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлү белән шәхесне раслаучы документ күрсәтәләр. Юридик затлар вәкилләре юридик затның дәүләт теркәве турында таныклык, вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документлар, шәхесләрен раслаучы документлар күрсәтәләр.

47. Теркәлмәгән затлар гади мәгълүмат бирү формасында иҗтимагый фикер алышуга кертелми.

48. Гади мәгълүмат бирү әлеге тәртипнең 3 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән проектлар турында фикер алышуы уздырылган очракта үткәрелә.

49. Барлык искәрмәләр, тәкъдимнәр һәм комментарийлар әлеге тәртипнең 17 пункты нигезендә теркәлә.

50. Гади мәгълүмат бирү формасында үткәрелгән иҗтимагый фикер алышу беркетмәсендә булырга тиеш:

1) иҗтимагый фикер алышу объекты;

2) гади мәгълүмат бирү формасында иҗтимагый фикер алышу датасы, урыны һәм вакыты турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү ысулы;

3) гади мәгълүмат бирү формасында иҗтимагый фикер алышу уздырыласы көнгә кадәр 20 календарь көн һәм гади мәгълүмат бирү формасында иҗтимагый фикер алышу уздырылган көннән соң 10 календарь көн эчендә гади мәгълүмат бирү формасында иҗтимагый фикер алышу объекты буенча материалларның урыны (шул исәптән заказчы карары буенча “Интернет” челтәрендә) һәм җәмәгатьчелек өчен ачык булу вакыты;

4) гади мәгълүмат бирү формасында иҗтимагый фикер алышу көне, вакыты һәм урыны;

5) гади мәгълүмат бирү формасында иҗтимагый фикер алышуда катнашучыларның гомуми саны;

6) җәмәгатьчелек һәм заказчы (башкаручы) арасында фикер каршылыклары предметы (булган очракта);

7) җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны аныклаучы башка мәгълүмат.

## 7 бүлек. Сораштыру формасында һәм башка формаларда иҗтимагый фикер алышу

51. Сораштыру формасында һәм башка формаларда иҗтимагый фикер алышуда әлеге тәртипнең 24 пунктында күрсәтелгән затлар катнаша ала.

52. Сораштыру формасында һәм башка формаларда иҗтимагый фикер алышуда катнашучы физик затлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлү белән шәхесне раслаучы документ күрсәтәләр. Юридик затлар вәкилләре юридик затның дәүләт теркәве турында таныклык, вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документлар, шәхесләрен раслаучы документлар күрсәтәләр.

53. Әлеге тәртипнең 52 пунктындагы мәгълүматларны күрсәтмәгән затлар сораштыру формасында һәм башка формаларда иҗтимагый фикер алышуда катнашмый.

54. Сораштыру формасында иҗтимагый фикер алышу җәмәгатьчелеккә иҗтимагый фикер алышу объекты белән танышу өчен материаллар урнаштыру урынын, сораштыру кәгазен күрсәтеп, искәрмәләр, тәкъдимнәр һәм комментарийларны сораштыру кәгазендә җыю һәм сораштыру беркетмәсе рәсмиләштерү тәртибендә үткәрелә.

55. Сораштыру билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек мәсьәләләре буенча халыкның фикерен ачыклау һәм аны исәпкә алу максатыннан үткәрелә.

56. Сораштыру үткәрү - сораштыру формасында һәм башка формаларда иҗтимагый фикер алышуда катнашучыларның әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү материаллары белән алдан таныштыруны күздә тота.

57. Сораштыру формасында һәм башка формада иҗтимагый фикер алышуда катнашучыларны иҗтимагый фикер алышу материаллары белән таныштыруны заказчы иҗтимагый фикер алышуга датасына кадәр 30 көн алдан тәэмин итә.

58. Иҗтимагый фикер алышу үткәрү комиссиясе гражданнарны сораштыру процедурасын әзерли һәм үткәрә.

59. Сораштыру Башкарма комитет карарында билгеләнгән чорда һәм вакытта сораштыру кәгазен тутыру юлы белән үткәрелә.

60. Сораштыру кәгазьләре сораштыру кәгазьләрен теркәү журналында теркәлә.

61. Сораштыру тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә иҗтимагый фикер алышу үткәрү комиссиясе әгъзалары сораштыру нәтиҗәләрен сораштыру кәгазьләрендәге мәгълүматларны эшкәртү юлы белән исәпләп чыгаралар.

62. Иҗтимагый фикер алышуда катнашучының позициясе күрсәтелмәгән: куелган сорауларга җаваплар һәм (яки) иҗтимагый фикер алышу объектына карата искәрмәләр, тәкъдимнәр һәм комментарийлар булмаган сораштыру кәгазьләре гамәлдә түгел дип санала.

63. Алынган нәтиҗәләр нигезендә сораштыру формасында иҗтимагый фикер алышу беркетмәсе төзелә, ул түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

1) иҗтимагый фикер алышу объекты;

2) сораштыру үткәргәндә фаразланган сорау (сораулар);

3) сораштыру үткәрү вакыты, сораштыру кәгазьләрен урнаштыру һәм җыю урыны турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү ысулы, шул исәптән электрон рәвештә;

4) алынган сораштыру битләре саны;

5) гамәлдә түгел дип танылган сораштыру битләре саны;

6) сораштыру нәтиҗәләре, шул исәптән куелган сорауларга өстәмә позицияләр, иҗтимагый фикер алышу объекты буенча искәрмәләр, тәкъдимнәр һәм комментарийлар

64. Кергән барлык алынган искәрмәләр, тәкъдимнәр һәм комментарийлар әлеге тәртипнең 17 пункты нигезендә теркәлә.

65. Сораштыру рәвешендәге иҗтимагый фикер алышу беркетмәсенә әлеге тәртипкә кушымта итеп бирелгән сораштыру кәгазьләре теркәлә (дистанцион форматта сораштыру үткәрү очракларыннан тыш, сораштырылучы, заказчы (башкаручы) вәкилләре һәм комиссия әгъзалары тарафыннан тутырыла һәм имзалана) һәм аларда сорауларның асылы буенча тикшерүгә чыгарыла торган мәсьәләнең аңлашылмаучанлыкка юл куймаслык ачык һәм дөрес формулировкалары; иҗтимагый фикер алышу объекты буенча сораштыруда катнашучының позициясен (комментарийларын, искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен) ирекле формада язу өчен буш урын була), аларны җыю юлы белән иҗтимагый фикер алышу объектын урнаштыру адресы буенча яки хәбәрдә күрсәтелгән башка адрес буенча, шулай ук хәбәр итүдә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча иҗтимагый фикер алышу срогында җәмәгатьчелекнең искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен кабул итү гамәлгә ашырыла.

66. Иҗтимагый фикер алышуның башка формасы җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирүне тәэмин итү, иҗтимагый фикер алышу объекты белән танышу һәм фикер алышу өчен материаллар урнаштыру урынын күрсәтеп, конференция, түгәрәк өстәл, анкета, җәмәгатьчелек белән консультация форматында, шулай ук бу пунктта күрсәтелгән формаларны берләштереп, иҗтимагый фикер алышу объекты буенча искәрмәләр, комментарийлар һәм тәкъдимнәр җыю юлы белән үткәрелә.

67. Иҗтимагый фикер алышу башка формаларда үткәргәндә катнашучылар чиратлап иҗтимагый фикер алышу объекты буенча үз фикерләрен белдерәләр.

68. Анкета формасындагы иҗтимагый фикер алышу сораштыру формасындагы иҗтимагый фикер алышуларына охшаш итеп үткәрелә.

69. Иҗтимагый фикер алышуның башка формасы беркетмәсендә булырга тиеш:

1) иҗтимагый фикер алышу объекты;

2) иҗтимагый фикер алышу датасы, урыны һәм вакыты турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү ысулы;

3) иҗтимагый фикер алышу уздырыласы көнгә кадәр 20 календарь көннән дә ким булмаган һәм гади мәгълүмат бирү формасында иҗтимагый фикер алышу уздырылган көннән соң 10 календарь көннән дә ким булмаган вакыт эчендә иҗтимагый фикер алышу объекты буенча материалларның урыны (шул исәптән заказчы карары буенча “Интернет” челтәрендә) һәм җәмәгатьчелек өчен ачык булу вакыты;

4) иҗтимагый фикер алышу көне, вакыты һәм урыны;

5) иҗтимагый фикер алышуда катнашучыларның гомуми саны;

6) җәмәгатьчелек һәм заказчы (башкаручы) арасында фикер каршылыклары предметы (булган очракта);

7) җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны аныклаучы башка мәгълүмат.

Экологик экспертиза узарга тиешле
билгеләнгән хуҗалык һәм башка
эшчәнлек турында иҗтимагый фикер
алышуны оештыру һәм үткәрү тәртибенә
кушымта

СОРАШТЫРУ БИТЕ

сораштыру формасында иҗтимагый фикер алышу үткәрелә торган
экологик экспертиза объекты – ______________________________________
әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүгә техник бирем һәм әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү материалларын кертеп

Сораштыруда катнашучы турында мәгълүмат

1. Ф.И.А.и. ______________________________________________________________
_____________________________________________________________________

2. Эш урыны _________________________________________________________
_____________________________________________________________________

3. Яшәү урыны ____________________________________________
_____________________________________________________________________

4. Контакт мәгълүматлары (тел, e-mail) ____________________________________
_____________________________________________________________________

5. Оешманың исеме, адресы, телефоны ___________________________
_____________________________________________________________________
*(иҗтимагый фикер алышуда катнашучы оешманы тәкъдим иткән очракта, тутырыла)*

Халык арасында сораштыру үткәрү буенча сорау:
________________________________________ проект документлары буенча сорауларыгыз, искәрмәләрегез һәм (яки) тәкъдимнәрегез бармы?

☐ Әйе

☐ Юк

(уңай җавап булган очракта, катнашучының сораулары, искәрмәләре һәм (яки) тәкъдимнәре әлеге сораштыру кәгазенең тиешле бүлегендә бирелә яки аңа аерым кушымта рәвешендә рәсмиләштерелә)

Сораштыруда катнашучының сораулары, искәрмәләре һәм (яки) тәкъдимнәре:
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

Сораштыру кәгазенә кушымта:
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

*(кушымта исеме)*

____________________________________________________________

________биттә

*(сораштыруда катнашучының сораулары, искәрмәләре, тәкъдимнәре булганда аерым битләрдә тутырыла катнашучының шәхси имзасы белән рәсмиләштерелә),*

Дата ___________________________ Имза ___________________________

Сораштыру кәгазен имзалап, иҗтимагый фикер алышуда катнашучы «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә үзенең ризалыгын белдерә.».

Сораштыру кәгазен алган затның Ф.И.А.и.,
вазыйфасы.

____________________________________________

________________________________________________________________________

«_____» __________20__ ел

Катнашучының сораштыру кәгазен тутыру тәртибе:

Сораштыру кәгазе сораштыру үткәрелә торган сораудан түбән урнашкан буш шакмакларның берсенә билге кую юлы белән тутырыла һәм сораштыруда катнашучы тарафыннан имзалана.

Уңай җавап булганда, катнашучының сораулары, искәрмәләре һәм (яки) тәкъдимнәре әлеге сораштыру кәгазенең «Сораштыруда катнашучының сораулары, искәрмәләре һәм (яки) тәкъдимнәре» бүлегендә яки аңа аерым кушымта рәвешендә иркле формада рәсмиләштерелә.

Бу тәртипкә туры килмәгән сораштыру кәгазьләре гамәлдә түгел дип танылa.